ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

«03» апрель 2024 ел Иске Дөреш авылы № 12

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче Салих-Тукай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 13 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 13 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Салих-Тукай авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Салих-Тукай авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 октябрендәге 8/1 номерлы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче Салих-Тукай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 13 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 13 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Салих-Тукай авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 16 апреленә 15.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче Салих-Тукай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 13 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Салих-Тукай авылындагы чишмәне төзекләндерү);

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 13 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Иске Дөреш авылында гражданнар җыены карарына:

«-җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Салих-Тукай авылындагы чишмәне төзекләндерү)

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Иске Дөреш авыл җирлеге, Салих-Тукай авылы, Комсомольская ур., 1 йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Иске Дөреш авыл җирлеге Башлыгы Р.М. Дусадбеков